**ГЛАВА ЧЕРНЫШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422710, Высокогорский район РТ,
д.Чернышевка, ул. Клубная, 1
Тел./факс: +7(84365) 73-5-05,
e-mail: Chern.Vsg@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЧЕРНЫШЕВКА АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

422710, ТР Биектау районы,
Чернышевка авылы, Клубная ур., 1
Тел./факс: +7(84365)73-5-05,
e-mail: Chern.Vsg@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

09 сентябрь 2025 ел № 17

16:16:320705:8138 кадастр номерлы җир кишәрлекләреннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Чернышевка авыл җирлеге Уставының 19 статьясы, Чернышевка авыл җирлеге Советының 01.04.2019 ел № - лы карары белән расланган гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә 177, авыл җирлеге территориясендә урнашкан җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектлары хокук ияләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү максатларында, карар бирәм:

1. 16:16:320705:8138 кадастр номеры булган җир кишәрлекләреннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы проектны гавами тыңлауларны билгеләргә

Үткәрү датасы һәм вакыты: 2025 елның 30 сентябрендә 09.00 сәгатьтә.

Үткәрү урыны: Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Чернышевка авылы, Клубная ур., 1 й.

Гавами тыңлауларда карала торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр язма рәвештә 2025 елның 29 сентябренә кадәр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Татарстан Республикасы, Биектау районы, Чернышевка авыл җирлеге, Чернышевка авылы, Клубная ур., 1 й.

Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә): Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Чернышевка авылы, Клубная урамы, 1 йорт; Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Чернышевка авыл җирлеге Башлыгы О.А.Маланин

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Чернышевка авыл җирлеге Советы башлыгы 2025 елның 09 сентябрендәге 17 нче карарына 1 нче Кушымта

**Гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибе**
**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының "Чернышевское авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектына**

1. Тәкъдимнәр Биектау муниципаль районының Чернышевка авыл җирлеге Советына түбәндәге адрес буенча кертелә: Татарстан Республикасы, Биектау районы, Чернышевка авылы, Клубная урамы, 1 йорт яисә 8 (84365) 73-5-05 факсимиль элемтә юлы белән язма рәвештә кушымтада бирелә торган үрнәктәге төзәтмәләр таблицасы рәвешендә:

| № п/п | Әйдәүче кертемнәр җөмләләр | Кертем-нәр датасы | Абзац, нокта, кал-дык, маддә | Про-ектнын тексты | Тәкъдим | Проект текстын исәпкә алып кертелгән тәкъдим | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |

2. Тәкъдимнәр 2025 елның 29 сентябренә кадәр эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр кабул ителә.

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Чернышевка авыл җирлеге Советы башлыгы 2025 елның 09 сентябрендәге 17 нче карарына 2 нче Кушымта

**Тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эшче төркем составы**

1. Маланин О.А. - комиссия рәисе, Чернышевка авыл җирлеге башлыгы
2. Даутова Ф.Р. - комиссия секретаре, Чернышевка авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре.
3. Тазеев К.А. – комиссия әгъзасы, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Чернышевка авыл җирлеге Советы депутаты
4. Хасанов А.Р. – Биектау муниципаль районының Мөлкәт һәм җир бүленешләре палатасы рәис вазифаларын башкаручы (килешү буенча).
5. Хисамутдинов Р.Ш. - «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының җитәкче урынбасары (килешү буенча)